Минзәлә гимназиясе укучылары газетасы

# ЯШЬЛЕК

Ноябрь 2025

## Бу санда:


2 -3 битләр - Әниләр көне

4 бит- “Татарча диктант” акциясе

5-7 битләр- фотоконкурс материаллары

8 бит – “Яңа шәхес” рубрикасы

9 бит – гимназия яңалыклары


***Әнием минем матур,***
***күзләре якты, көләч.***
***Шундый күңелле була,***
***ул өйгә кайтып кергәч.***

***Мин елышам әнигә,***
***әни миңа елыша.***
***Битләре аның кайнар,***
***ә куллары йоп-йомшак.***

***Конфет та кирәк түгел,***
***кирәк түгел курчак та,***
***Чөнки мин әниемне***
***алдым инде кочаклап.***







**“Россия ел укытучысы” бөтенроссия конкурсының муниципаль этабы нәтиҗәләре белән газетабызның 3нче битендә таныша аласыз.**




**Бу бүләк - зур коллективның - укучыларның, ата-аналарның һәм педагогларның гомуми казанышы.**

# Әниләр көне



Кадерле әнием, син минем тормышымда иң мөһим кеше. Синең җылың, кайгыртуың һәм мәхәббәтең һәрвакыт янәшәмдә Мин сиңа барысы өчен дә бик рәхмәтле. Син миңа тормышта дөрес юл күрсәтәсең һәм һәрвакыт ышаныч бирәсең. Сиңа ныклы сәламәтлек, бәхетле көннәр һәм озын гомер телим. Мин сине чиксез яратам, әнием! Улың Альмир.

*****

Минем әнимнең исеме - Чулпан. Әниемә 29 яшь. Аның эш урыны "Кино театр ". Әниемне безне торт, чебурек һәм башка төрле тәм - томнар белән сыйлый. Ул - безнең бик яраткан һәм хөрмәтле кешебез! Әнием, без сине бик нык яратабыз! Бәйрәм белән сине, әнием! Кызың Азалия.

*****

Минем әниемнең исеме - Рушания. Минем өчен әнием- иң матур, иң уңган кеше. Мин әниемне бик яратам, чөнки минем өчен аннан да кадерле кеше юк. Әнием бик оста ашарга пешерә. Ул һәр кешегә булыша. Сәламәт бул, мәңге яшә, сабыр, тыйнак, уңган - булган әнием.ниләр көне белән сине котлыйм. Кысып кочаклап, яраткан кызың Айсылу.

*****

Минем әниемнең исеме - Лилия, ул 1994 елның 23 нче гыйнварында туган. Аңа 31 яшь. Ул балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Хәзерге вакытта ул декрет ялында. Минем әнием иң матуры, иң сөйкемлесе, иң уңганы. Аның кулыннан бар эштэ килә. Пешергән ризыклары гына ни тора, телеңне йотардай буласың. Мин әниемне бик яратам һәм хөрмәт итәм. Кызың Зәринә.

*****

Минем әниемнең исеме-Алинә. Аңа 32 яшь. Ул Минзәлә ветеринариясендә эшли. Ул бик тәмле пешерә. Бигрәк тә миңа аның бәрәңге белән пешергән пәрәмәчләре ошый. Әле тагын ул безне төрле тәмле салатлары белән сыйлый. Мин аны бик-бик яратам. Аның минем әнием булуы белән горурланам. Бәйрәмен котлы булсын, әнием! Кызың Лиана.

*****


Минем әниемнең исеме Алсу. Аңа 37 яшь. Хәзерге вакытта әнием эшләми. Өй эшләре белән шөгыльләнә, ә буш вакытта бәйләргә һәм тәмле ризыклар әзерләргә ярата. Әнием, сине ӘНИЛӘР көне белән котлыйм. Һәрвакыт сау-сәламәт бул, озак яшә. Кызың Юлия.

*****



Әнием, син - безнең гаиләбезнең йөрәге, җаныбызның җылысы. Синең сабырлыгың һәм олы йөрәгең миңа һәрвакыт үрнәк булып тора. Мин синең һәр сүзеңне, һәр киңәшеңне кадерлим. Сиңа нык сәламәтлек, кайгысыз гомер телим. Рәхмәт сиңа, әнием, барлык яхшылыкларың өчен! Кызың Самира.

*****



Минем әниемнең исеме - Ләйсирә. Әниемә 37 яшь. Аның эш урыны ГАУСО" Рц

Умырзая". Әнием безне бәлеш, тавык белән бәрәңге, кыстыбый һәм башка төрле тәм-томнар белән сыйлый. Ул безнең бик яраткан һәм хөрмәтле кешебез! Әнием, сине Әниләр көне белән котлыйм. Һәрвакыт көләч йөзле бул, сау-сәламәт яшә. Әнием, син- минем тормышымда иң якты нур, иң зур терәк. Синең җылың һәм мәхәббәтең һәрвакыт күңелемне җылыта. Мин сине бик нык яратам! Сиңа ныклы сәламәтлек, бәхетле, шатлыклы минутлар телим. Синең игелекле йөрәгең һәрвакыт шундый ук җылы булып калуын телим. Кызың Эльвира

*****



*****

Минем әниемнең исеме- Лилия. Аңа 38 яшь. Ул Россия Ислам институтында укый, гарәп телен өйрәнә. Бакчада гөлләр, яшелчәләр үстерергә ярата. Барлык ризыкларны да тәмле итеп пешерә. Ул- минем дустым, киңәшчем. Мин аны шундый нык яратам. Әнием! Сине Әниләр көне белән котлыйм. Сау-сәламәт бул, озак яшә. Кызың Исламия.

*****

Минем әниемнең исеме- Роза. Аңа 37 яшь. Ул баш хисапчы булып эшли. Минем әнием дөньядагы барлык әйберләрне дә бик тәмле итеп әзерли. Ул безнең- иң яраткан, иң кадерле кешебез! Әниләр көне белән, әнием! Йөзеңнән беркайчан да елмаю сүнмәсен! Сине яратып, кызың Азиза!

*****

Минем әниемнең исеме- Илзирә! Аңа 33 яшь. Ул “Победа” кинотеатрында методист булып эшли. Безнең гаиләдә 3 бала. Әнием бар эшкә дә өлгерә: тәмле итеп ашарга да пешерә, безнең белән шөгыльләнергә дә җитешә, безгә әкиятләр укый. Ял көннәрендә иртән торуга әнием тәмле итеп коймагын да пешереп куя. Минем әниемнең куллары алтын дияр идем мин. Өебез һәрвакыт чиста, миңа өйгә кайтуы да рәхәт. Әнием! Безне сөендереп озак яшә. Без үзебезнең матур эшләребез белән сине сөендереп кенә торырбыз. Без сине бик-бик яратабыз. Улың Ислам.

*****

Минем әниемнең исеме- Гөлчәчәк. Аңа 40 яшь. Ул “Балачак” исемле балалар бакчасында эшли. Эштән кайткач тәмле ашлар, бәлеш, кыстыбый һәм башка тәмле ризыклар пешерә. Без аны хөрмәт итәбез һәм бик яратабыз. Озын гомер сиңа телим, әнием! Кызың Таңсылу.

*****

**Җир йөзендәге иң кадерле, иң изге кеше - Әни... Бу якты дөньяга килгәч тә безне, йомшак куллары белән сыйпап, ак биләүгә биләүче, еласак, җыр көйләп юатучы, татлы йокыдан иркәләп уятучы, яшәргә көч-дәрт бирүче, гомер буена кайгы–шатлыкларыбызны уртаклашучы, тормышыбызның бизәге, таянычы, акыллы уй–фикерләре белән тормыш дигән олы юлдан алып баручы ул.**

**Нәкъ менә шул сыйфатлар җәмгыятькә әниләр көнен игълан итәргә сәбәп булгандыр. Илебездә билгеләп үтелә торган күпсанлы бәйрәмнәр арасында ӘНИЛӘР КӨНЕ аерым урын алып тора.**

**Ә әниләребезне бәйрәм белән котлап, ныклы сәламәтлек, озын гомер, рухи көч, тормыш зирәклеге, сабырлык, гаилә бәхете телибез!**

# “Татарча диктант” акциясе



Минзәлә гимназиясенең 4-11 нче сыйныф укучылары, ата-аналары, киң җәмәгатьчелек вәкилләре "Татарча диктант -2025" Халыкара акциясендә катнаштылар. Гимназия мәйданынчында 250 артык кеше бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри хезмәтеннән алынган текст буенча диктант



язды. Әлеге диктант текстының эчтәлегендә кешенең сөйләм куәте һөнәр дип бәяләнә, ир баланы татлы, мәгънәле, урынлы сөйләмгә өнди. Әти-әниләр өчен диктант текстын Татарстанның халык артисты Миннемуллина Илсинә Илшат кызы укыды. Укучылар һәм хезмәткәрләр өчен үзебезнең югары категорияле татар тел укытучысы Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы укыды. Шәһәребезнең зыялы вәкилләре: С. Өметбаев исемендәге татар дәүләт драма театры директоры Хизбуллин Ф. Г, мәгариф бүлеге җитәкчесе Ибраһимов Р. М., район методистлары, "Минзәлә" газетасының баш редакторы Шаһиев И., Минзәлә мәчете имамы Рәмзил хәзрәт акциядә балалар белән бергә парта артына утырып татарча диктант яздылар.

Быел үзебездә гаилә белән килгән гаиләләргә бүләк тә әзерләгән идек. Шаһиевлар, Галиевлар, Шигаповлар гаиләләр белән катнашты. Икенче елга да бу матур күренешне дәвам итәргә исәп.



# Фотоконкурс

## “ӘНИЕМ БЕЛӘН БЕРГӘ”




















POVA 6 Neo
23mm f/1.6 1/24s ISO457






# Фотоконкурс

**“Давыллы көннәрдә, ышыклап җилләрдән, күкрәгенә кыскан кем тагы? Кадерләп үстергән, яшәргә көч биргән ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ.”**



**4 буын вәкилләре: әби, әни, кызы һәм оныгы**



**әни үзенең балалары белән**



**Ике әби, әни һәм оныклар**



**4 буын вәкилләре: әби, әни, кызы һәм онықлары.**



**3 буын: әни, кызы һәм оныклары**



**3 буын: әни, кызы һәм оныгы**



**3 буын: әни, кызы, оныгы**

# “Яңа шәхес”

**Кыскача мәгълүмат:**
**Исеме:** Самигулин Марат Митхәт улы
**Туган көне:** 26 нчы август
**Шөгыльләре:** Бакчада эшләргә яратам.
**Яраткан ризыклары:** Пылау
**Яраткан фильмы:** Алар бик күп. Мин кешеләрнең тормышын, язмышларын чагылдырган мелодрамалар, полиция турындагы сериалларны карарга яратам.




- **Сез нинди уку йортын тәмамладыгыз?**
Үзбәкстандагы Термес дәүләт педагогия институтын тәмамладым. Минем һөнәрем- рус теле һәм әдәбияты укытучысы.

- **Сез үз эшчәнлегегезне кайда башладыгыз?**
1980 нче елда Үзбәкстанда рус теле укытучысы булып эшли башладым. 2000 нче елда гаиләм белән Татарстанга күченеп кайттык. Эшемне һөнәр училищесында дәвам иттем.

- **Сезгә гимназиядә эшләү ошыймы?**
Гимназиядә эшләү миңа бик ошый. Мин башка мәктәпләрдә эшләп карамадым. Гимназия совет мәктәбен хәтерләтә. Мин сезгә килгәнче кадет мәктәбендә эшләдем. Анда эш тәртибе башкача: укучылар көне буе укый, расписаниедә өстәмә дәресләр дә бар. Мин укучылар белән “Оста куллар” түгәрәге алып барам. Укучылар бик яратып йөриләр. Түгәрәккә йөрүчеләр агачтан эшләнгән материаллар белән эшлиләр: рәсем төшерәләр, махсус аппарат (выжигатель) белән эшлиләр, рәсемне бизиләр. Мин үзем дә бик яхшы рәсем ясыйм. Минем бу сыйфатым түгәрәкне оештыруга бик ярдәм итә. Мин эшемнән бик канәгать.

- **Сезгә тормышны яңадан башларга туры килсә, сез укытучы һөнәрен сайлар идегезме?**
Әлбәттә. Миңа укытучы һөнәре бик ошый. Миңа, бигрәк тә, балалар белән эшләү рәхәтлек бирә. Алар белән аралашу, аларга үземнең төпле киңәшләремне бирү, туплаган тәҗрибәм белән уртаклашу, балаларны ярату - болар барысы да мине мәктәп тормышына алып килә.

**-Әгәр сез миллион сум акча отсагыз, аны нишләтер идегез?**
Әлбәттә инде, үземнең балаларыма бирер идем. Минем бер кызым, бер улым, ике оныгым бар. Аларга рәхәтләнеп ярдәм итәр идем.



*Материалны Бокова Софья әзерләде*

# Гимназия сулышы

*****



Сәлам, сәлмм! Мин Зарипова Самира Илсур кызы һәм мин “Габдулла Тукай” исемендәге нәфис сүз конкурсында район этабында җиңүче булдым. Җиңүчеләрне «Волга» лагерында 12-15 ноябрьләрдә форумга җыйдылар. Анда төрле мастер-класслар, танылган шәхесләр белән очрашулар, кызыклы чаралар булды. Мин яңа дуслар таптым. Хәзер инде соңгы этап көтә, ул 2026 елның апрелендә узачак һәм мин аңа тырышып әзерләнәчәкмен. Барлык катнашучыларга дипломнар бирделәр. Ә без яшьтәшләребез һәм жюри алдында чыгыш ясау тәҗрибәсе тупладык.

*****




2025-2026 нчы уку елында **“Россия ел укытучысы”** бөтенроссия конкурсының муниципаль этабы тантаналы төстә тәмамланды. Гимназиядә районның иң яхшы педагогларын хөрмәтләү булды. Быел иң яхшылар исеменә 14



талантлы һәм иҗади педагог көрәште, алар шәһәр мәктәпләре мәйданчыкларында конкурс дәресләре үткәрде, мастер-класслар күрсәтте. Гимназиянең башлангыч сыйныф укытучысы Хамадиева Алия Айзат кызы “Педагогик дебют” номинациясендә җиңүче дип табылды.

*****



Гимназия укучылары Минзәлә районы мөхтәсибәте Җәмигъ мәчете каршында оештырылган «Җәннәт әниләрнең аяк астында» дип исемләнгән Әниләр көненә багышланган әхлакый чарада булдылар.

*****




"Көчле һәм уңышлы мәктәпләрне, коллегалары тигезләнә алырлык, эшне оештыруда тәҗрибә һәм нәтиҗәле практика алырга мөмкин булган көчле һәм уңышлы мәктәпләрне атарга һәм билгеләргә кирәк", - дип белдерде Рособрнадзор җитәкчесе Анзор Музаев. Татарстанның 54 мәктәбе арасында Минзәлә шәһәре Гимназиясе ФИОКО билгеләгән «Белем бирү оешмалары өчен сыйфат билгесе» дигән ике юнәлешнең берсе булган «Югары бәяләү культурасы» байрагына ия булды.